ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАРАКАШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Мирфатиха Закиева, д.47,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Мирфатыйх Зәкиев урамы, 47йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**№ 23** **30 октябрь 2015 ел**

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең коммуналь инфраструктурасы системасын 2015-2025 елларга комплексłы үстерү программасын раслау турында**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 30 декабрендәге «Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын җайга салу нигезләре турында»гы 210-ФЗ санлы Федераль закон, 2009 елның 23 ноябрендәге «Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 261-ФЗ санлы Федераль закон, 2010 елның 27 июлендәге "Җылылык белән тәэмин итү турында"гы 190-ФЗ санлы Федераль закон, 2010 елның 2 февраленнән «2010-2020 елларга Торак-коммуналь хуҗалыкны модернизацияләү һәм реформалауның комплексłы программасы «Федераль максатчан программасы концепциясен раслау турында»гы 102-р санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма комитеты **карар бирә:**

1. 2015-2020 елларга «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең коммуналь инфраструктурасы системасын комплексłы үстерү программасын кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

ИНН 1642004804

Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Дәүләтгәрәев

Зарипова Р.В.
4-21-34

Карарга КУШЫМТА

# 2015-2020 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программасы

## ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның Исеме | 2015-2020 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программасы |
| Программа эшләү турында Карар кабул итү нигезе | 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131 – ФЗ санлы Федераль закон; |
| Заказчы | 2004 елның 30 декабрендәге «Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын җайга салу нигезләре турында»гы 210 – ФЗ санлы Федераль закон; |
| Программаның төп эшләүчеләре | 2009 елның 23 ноябрендәге «Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 261 – ФЗ санлы Федераль закон<br>ТР Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитеты |
| Программаны Башкаручылар | ТР Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитеты |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | ТР Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитеты |

## 1. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа методлары белән хәл итү кирәклеген нигезләү

Әлеге Программа 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131 – ФЗ санлы, 2004 елның 30 декабрендәге «Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын җайга салу нигезләре турында»гы 210 – ФЗ санлы, 2009 елның 23 ноябрендәге «Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 261 – ФЗ санлы Федераль законнар нигезендә эшләнгән. 2015-2020 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программасы (алга таба - Программа) коммуналь билгеләнештәге объектларны реконструкцияләү, модернизацияләү һәм комплекслы яңарту механизмнарын гамәлгә кертүне күздә тота.

Программа төп фондларның нормативтан тыш тузуын бетерү бурычларын хәл итү, ресурсларны саклау технологияләрен кертү, шулай ук торак-коммуналь предприятиеләрнең нәтиҗәле һәм рациональ хуҗалык итүен стимуллаштыру чараларын эшләү һәм киң кулланылышка кертүне, кулланучыларга ышанычлы һәм тотрыклы хезмәт күрсәтү бурычларын хәл итү өчен үз ресурсларыннан максималь файдалануны күздә тота. Гамәлдәге электр белән тәэмин итү, су белән

тәэмин итү, ташландык суларны агызу, җылылык белән тәэмин итү системасын капиталь ремонтлау Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге халкы мәнфәгатьләренә җавап бирә һәм торак-коммуналь инфраструктураны функцияләүнең базар механизмын формалаштырырга мөмкинлек бирәчәк. Гамәлдәге электр белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, җылылык белән тәэмин итү системасына капиталь ремонт ясау - торак-коммуналь хуҗалык объектларының эксплуатация күрсәткечләрен яхшырту максатларында, аларны озынрак һәм экономияле итеп алмаштыру буенча эшләр башкару. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең җирле бюджет мөмкинлекләре чикле булу сәбәпле, торак-коммуналь хуҗалык объектларын үзгәртеп кору, модернизацияләү һәм капиталь ремонтлау проблемасын мөстәкыйль хәл итү мөмкинлеге булмау сәбәпле, программа чараларын финанслауны республика, район һәм җирле бюджет акчалары, кулланучылар һәм бюджеттан тыш чыганаклар өчен бәяләргә (тарифларга) җайга салына торган өстәмәләр исәбенә алынган акчалар хисабына гамәлгә ашырырга кирәк.

## 2. Программаның максатлары һәм бурычлары

Программаның төп максаты: төп фондларның гомуми тузу дәрәҗәсен киметү, күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту.

Әлеге максатны тормышка ашыру түбәндәге бурычларны хәл итүне күздә тота:

- энергия белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу системаларын эксплуатацияләгәндә һәм халыкны газ белән тәэмин итү системасын керткәндә югалтуларны киметү.

## 3. Программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары

Программа 2015-2020 елларда тормышка ашырыла.

## 4. Инженерлык инфраструктурасы торышын бәяләү

4.1. Су белән тәэмин итү

Кәрәкәшле авылында су белән тәэмин итүне «Урыссу-Водоканал» ҖЧҖ башкара. Предприятие балансында ике су алу җайланмасы бар: Чатра һәм Аксакүл.

Су челтәренең гомуми озынлыгы.

Кәрәкәшле тимер юл разъезды бистәсендә һәр шәхси хуҗалыкта колонка бар.

4.2. Электр белән тәэмин итү

Кәрәкәшле авыл җирлегенең электр белән тәэмин итү системасы үзәкләштерелгән. Электр белән тәэмин итүнең төп чыганаклары булып бүлү подстанцияләре (РПС)тора:

Егәрлекне авыл җирлегенең торак пунктларына, шулай ук күрше муниципаль берәмлекләргә бүлү һәм транзитлау, нигездә, 6кВ электр линияләре буенча башкарыла.

Авыл җирлегенең электр белән тәэмин итү системасы үзәкләштерелгән объектлардан кала:

Кәрәкәшле авыл җирлегенең төп үзәкләштерелгән электр белән тәэмин итү чыганагы булып 863кВ. бүлү подстанцияләре тора.

4.3. Газ белән тәэмин итү

Кәрәкәшле халкын газ белән тәэмин итү гамәлдәге газүткәргеч аша бер иярчен газ белән башкарыла. Кәрәкәшле тимер юл разъезды бистәләрен газ белән тәэмин итү сыекландырылган баллон газы белән башкарыла.

## 5. Программаның төп чаралары исемлеге

Программаның төп чаралары программаның максатларына ирешүгә юнәлдерелгән-төп фондларның гомуми тузу дәрәҗәсен киметү, күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту.

Оештыру чараларын күздә тота:

- үзгәртеп корылырга, модернизацияләнергә, капиталь төзекләндерелергә тиешле объектлар исемлеген формалаштыру (1 нче кушымта);

-күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын тәэмин итү максатларында коммуналь инфраструктура объектларын өлешләп төзүне, үзгәртеп коруны, модернизацияләүне һәм капиталь ремонтлауны гамәлгә ашыру өчен җирле бюджеттан бүлеп бирелә торган акчаларның еллык күләмен билгеләү.

Программага кертелгән коммуналь инфраструктура объектларын капиталь ремонтлау программаның гамәлдә булу срогы чикләрендә тәмамланырга тиеш. Программа чараларын тормышка ашыру нәтиҗәсендә су белән тәэмин итү буенча күрсәтелә торган коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын яхшыртуда чагылдырыла торган уңай социаль-икътисади нәтиҗәгә ирешеләчәк. Программаны тормышка ашыруның уңай нәтиҗәсе буларак, күрсәтелә торган коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын күтәрү белән бәйле рәвештә, халыкның яшәү шартларын яхшырту нәтиҗәсендә, социаль киеренкелекне киметү булачак. Коммуналь инфраструктураны үстерү су белән тәэмин итү буенча өстәмә хезмәтләр күрсәтүгә ихтыяҗны тәэмин итәргә, шулай ук кулланучыларга коммуналь хезмәтләрне өзлексез рәвештә сыйфатлы итеп күрсәтергә мөмкинлек бирәчәк.

## 6. Программаны тормышка ашыру механизмы

Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитеты әлеге программа кысаларында:

- гомуми җитәкчелек итүне, программаны гамәлгә ашыруны координацияләүне һәм тикшереп торуны гамәлгә ашыра;
- программага кертелергә тиешле объектлар исемлеген формалаштыра (№1 кушымта);
- коммуналь инфраструктура объектларын төзү, реконструкцияләү, модернизацияләү һәм капиталь ремонтлау өчен проект-смета документациясен эшләүне тәэмин итә;
- башкаручылар белән коммуналь инфраструктура объектларын төзү, реконструкцияләү, модернизацияләү һәм капиталь ремонтлау өчен проект-смета эшләрен башкаруга 2005 елның 21 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә

заказлар урнаштыру турында»гы 94-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә кирәкле контрактлар төзи;
- программаны гамәлгә ашыру күләмнәре һәм акчаларны югары органнарга тоту турында хисаплар бирә.

## 7. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программа чараларын финанслау, республика бюджеты, район бюджеты, башка финанслау чыганаклары хисабына башкарыла. Программаны финанслау финанслашу шартларында җирле бюджетка дотацияләр рәвешендә республика һәм район бюджетларыннан финанслауны күздә тота.

2015-2020 елларга Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм чираттагы финанс елына бюджет кабул ителгәннән соң билгеләнгән тәртиптә ел саен төгәлләштерелергә тиеш.

## 8. Программаны тормышка ашыру белән идарә итү һәм аның үтәлешен контрольдә тоту

Заказ бирүче программаны тормышка ашыру барышын контрольдә тота, программа чараларын әзерләү һәм тормышка ашыру, бюджет акчаларын максатчан һәм нәтиҗәле файдалану буенча гамәлләрне килештерүне тәэмин итә, җирле бюджеттан һәм башка дәрәҗәләрдәге бюджетлардан финанслау өчен билгеләнгән тәртиптә бюджет гаризасы әзерли һәм тапшыра, шулай ук Хисап елы өчен Программаны гамәлгә ашыруның барышы турында мәгълүмат әзерли.

Программаны тормышка ашыру һәм алар тарафыннан бүлеп бирелә торган финанс чараларын рациональ файдалану, тормышка ашырыла торган программа чараларының сыйфаты, муниципаль контрактларны үтәү сроклары турындагы вакытлы хисапны үз эченә ала.

Программа чараларын башкаручылар билгеләнгән тәртиптә заказчы алдында үзләренә бүлеп бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалану турында хисап тота.

Программага төзәтмәләр кертү, шул исәптән аңа яңа чаралар кертү, шулай ук аны гамәлгә ашыру вакытын озайту заказчы, программаны эшләүчеләр тәкъдиме буенча билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

## 9. Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны уңышлы тормышка ашыру түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:
- җирлек халкын коммуналь хезмәтләрне (су белән тәэмин итү)өзлексез, куркынычсыз күрсәтү белән тәэмин итү;;
-тузган суүткәргеч челтәрләрен һәм җирлекнең башка торак-коммуналь хуҗалык объектларын этаплап торгызу;
- су белән тәэмин итү системасында ел саен су югалтуларын киметергә.